**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**25.10.2023** **1629**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен уздыруга проект документациясен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 16 февралендәге 238 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Прокуратурасының 2023 елның 01 февралендәге 02.08-01 номерлы протесты нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен уздыруга проект документациясен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 16 февралендәге 238 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.2.1 пунктчаның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган мөрәҗәгатьне формат-логик тикшерүне орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формадагы мөрәҗәгатьнең һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал гамәлгә ашыра. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы мөрәҗәгатьнең корректлы тутырылмаган кыры ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр итү юлы белән турыдан-туры мөрәҗәгать итүнең электрон формасында хәбәр ителә.»;

1.2. 2.16. бүлекнең 2.16.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктчасын өстәргә:

«7) Бердәм портал кулланып, машина укый ала торган форматта орган (оешма) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ алырга.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында

http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин